КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 23 гыйнвар г.Казань № 35

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 15 июнь, 564 нче карары белән расланган Гомумтаралган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен яки берләштерелгән лицензия буенча аларны геологик өйрәнүне, разведкалауны һәм чыгаруны гамәлгә ашыру өчен, эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә кулланыла торган су белән тәэмин итүгә яки техник су белән тәэмин итүгә файдаланыла торган җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү өчен, җир асты суларын разведкалау һәм чыгару өчен яки җир асты суларын эзләү һәм бәяләү, аларны чыгару максатларында геологик өйрәнү өчен, коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләрен һәм (яки) коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтләрен эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә кулланыла торган су белән тәэмин итүгә яки техник су белән тәэмин итүгә файдаланыла торган җир асты суларын чыгару өчен, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен файдалануга бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гомумтаралган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау

һәм чыгару өчен яки берләштерелгән лицензия буенча аларны геологик өйрәнүне, разведкалауны һәм чыгаруны гамәлгә ашыру өчен, эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә кулланыла торган су белән тәэмин итүгә яки техник су белән тәэмин итүгә файдаланыла торган җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү өчен, җир асты суларын разведкалау һәм чыгару өчен яки җир асты суларын эзләү һәм бәяләү, аларны чыгару максатларында геологик өйрәнү өчен, коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләрен һәм (яки) коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтләрен эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә кулланыла торган су белән тәэмин итүгә яки техник су белән тәэмин итүгә файдаланыла торган җир асты суларын чыгару өчен, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен файдалануга бирү тәртибе» 2022 ел, 15 июнь, 564 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 18 август, 855 нче; 2022 ел, 29 сентябрь, 1050 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гомумтаралган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен яки берләштерелгән лицензия буенча аларны геологик өйрәнүне, разведкалауны һәм чыгаруны гамәлгә ашыру өчен, эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә кулланыла торган су белән тәэмин итүгә яки техник су белән тәэмин итүгә файдаланыла торган җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү өчен, җир асты суларын разведкалау һәм чыгару өчен яки җир асты суларын эзләү һәм бәяләү, аларны чыгару максатларында геологик өйрәнү өчен, коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләрен һәм (яки) коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтләрен эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә кулланыла торган су белән тәэмин итүгә яки техник су белән тәэмин итүгә файдаланыла торган җир асты суларын чыгару өчен, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен файдалануга бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктның «б» пунктчасындагы тугызынчы абзацында «гомумтаралган файдалы казылмалар булган» сүзләреннән соң «һәм җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлегенә кертелгән» сүзләрен өстәргә;

5.1 пунктның «е» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«е) әгәр заявка бирү датасына соңгы хисап чоры өчен бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын бирү сроклары чыкмаган булса, заявка бирү датасына кадәрге соңгы хисап чоры өчен яки заявка бирү датасына кадәрге үткән хисап чоры өчен бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы күчермәсе (барлык мәҗбүри формаларны теркәп) – салым органының аны кабул итү турындагы билгесе белән яки Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә расланган, салым органының бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын кабул итүен раслый торган квитанцияләрне (булганда) теркәп;»;

5.9 пунктта:

беренче абзацта «5.1 пунктындагы «и» сүзләрен «5.1 пунктындагы «м» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле «ж» пунктчасын өстәргә:

«ж) җир асты суларын чыгару буенча күрсәтелгән күләмне нигезләү исәп-хисабы.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин